**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава Нижнетимерлекского сельского поселения**
**Рыбно-Слободского муниципального района**
Индекс422670 с.Верхний Тимерлек, ул.Советская, дом 4А,

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән**
**Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгы**
индекс 422670.Югары Тегермәнлек авылы, Совет ур. 4А йорт

Тел.: (84361) 28001, факс: (84361) 28001, эл.адрес: Ntim.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

. 2019 елның 18 октябре Югары Тегермэнлек авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы " Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыененың беренче этабын 2019 елның 29 октябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Югары Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыененың икенче этабын 2019 елның 30 октябрендә 13 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыененың беренче этабын 2019 елның 29 октябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыененың икенче этабын 2019 елның 30 октябрендә 11 сәг. 00 минутка билгеләргә.
5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлү территориаль билге буенча гамәлгә ашырылуын расларга.
6. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек

авыл җирлеге Түбән Тегермәнлек авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан,80 яше тулган гражданнардан гайре,) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Югары Тегермәнлек авылында Титов урамы юллар ремонты өчен вакланган таш сатып алуга;

- Югары Тегермәнлек,Түбән Тегермәнлек авылларына конкүреш калдыклары җыю мәйданчыгы ясау,контейнерлар сатып алуга тоту;

"ЯКЛЫЙМ" "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Югары Тегермэнлек авылы, Совет урамы, 72 А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда.

7. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге башлыгы А.Н.Дмитриев